**СОВЕТ ЛЕНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЛЕНИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

ул. 40 лет Победы д. 32,
с. Ленино,423181

Җиңүнең 40еллыгы урамы, 32,
Ленино авылы, 423181

тел.: (8-4348) 3-44-16, факс: (8-4348) 3-44-10; Lenin.nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль
районы Ленино авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2026 елның 31 нче марты № 7-20

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге Советының 9.04.2020 елның 72-146 номерлы «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының 2025 елның 31 декабрендәге 1009 номерлы Указы, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Ленино авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Ленино авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленин авыл җирлеге Советының 9.04.2020 ел, № 72-146 карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге Советы карарлары редакциясендә: 15.06.2020 № 74-151, 26.03.2021 № 9-23, 2.07.2021 № 14-35, 31.05.2022 № 25-71, 6.03.2023 № 34-101; 24.08.2023 № 40-117; 8.04.2024 № 46-137; 24.10.2024 № 50-146, 24.10.2025 № 2-8;) (алга таба-Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 7 бүлек 7.3 өлешнең 10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«10) «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр;»;

1.2. Нигезләмәнең 19 бүлегендә:

а) 19.1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«19.1. Муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы граждан, муниципаль хезмәткәр әлеге Федераль законда билгеләнгән очракларда яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законда каралган белешмәләрне тапшыралар. Күрсәтелгән белешмәләр Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән тәртиптә, срокларда һәм формада тапшырыла.»;

б) 19.2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19.2. Тиешле исемлеккә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче муниципаль хезмәткәр «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба - «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» Федераль закон) каралган чыгымнар хакында белешмәләрне Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан мондый белешмәләрне тапшыру өчен билгеләнгән тәртиптә һәм форма буенча.»;

в) 19.3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19.3. Муниципаль хезмәткәрнең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законда һәм «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» Федераль законда, Россия Федерациясе Президентының норматив хокукый актларында, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексында, норматив хокукый актларда каралган тәртиптә, Татарстан Республикасы Башлыгы (рәисе) актлары, муниципаль хокукый актлар белән гамәлгә ашырыла.»;

г) 19.4 өлештә «керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында» сүзләрен төшереп калдырырга;

д) 19.5 өлешнең беренче абзацында. «керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне» сүзләрен «әлеге статья нигезендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрне» сүзләренә алмаштырырга.;

е) 19.5 өлешнең икенче абзацында. «керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне» сүзләрен «әлеге статья нигезендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрне» сүзләренә алмаштырырга.;

ж) 19.6 өлештә «чыгымнар керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне» сүзләрен «керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында» Федераль законда каралган белешмәләрне һәм «Дәүләт Вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында»,алыштарырга».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә: https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге Советының Социаль сәясәт һәм законлылык буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Ленино авыл җирлеге башлыгы

СОВЕТ ЛЕНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

С. Ю. Питеркина